Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы

КАРАР

2023 елның 09 октябрендәге № 166

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында«2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уставына ярашлы рәвештә, 2023 елның 23 сентябрендәге ачык тыңлаулар протоколларын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советы тарафыннан үткәрелгән һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында нәтиҗәләрне Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлегенең Генераль планын кушымта нигезендә электрон чыганакта расларга.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетына территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегенең Генераль планын урнаштыруны тәэмин итәргә (https://fgistp.economy.gov.ru/).

3. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге советына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлегенең генераль планын раслау турында элек кабул ителгән карарның үз көчләрен югалткан дип таныrга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре

порталы составында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Советының экология, аграр мәсьәләләр, табигый ресурслар һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Советы рәисе Н. А. Вазыйхов